ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район,
село Старые Киязлы, ул. Центральная д.56
Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 1061665002332,
ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001

**Карар**

№ 72 — 14 декабрь 2024 нче ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы "Иске Кыязлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 29.10.2019 ел №88 карары белән расланган (16.12.2021 ел №24; 12.04.2023 ел №48 карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы Карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 29.10.2019 ел, № 88 карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының "Иске Кыязлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә әлеге карарның текстын дәүләт теркәвенә алганнан соң «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының ТР, Аксубай районы, Иске Кыязлы авылы, Үзәк урам, 56 йорт адресы буенча урнашкан бинасындагы мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар дәүләт теркәвенә узгач һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы — Дәүләтшин Г. Г.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге
Советынын 14.12.2024 елгы
72 нче карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
"Иске Кыязлы авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:: "20) "шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.";
2. 19 статьяның 5 өлешендә "1-7 пунктчалары" сүзләрен "1-7 һәм 9 һәм 9.1 пунктчалары" сүзләренә алмаштырырга.;
3. 28 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: «1. Җирлек советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайлана торган 7 депутаттан тора.»
4. 33 статьяның 1 пунктындагы 30 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: «30) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) Челтәр басмасын булдыру;»;
5. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9,1 пункт өстәргә:: "9.1) аның чит ил агенты статусын алуы;";
7. 51 статьяның 9 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»
8. 48 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:: "6) аның чит ил агенты статусын алуы;". 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: "Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе" 71 статьясы
1. Кеше һәм гражданның хокукларына, иреклләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлеге булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып алар:
1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы сыйфатында теркәлү турында ФС77-60244 номерлы таныклык 17.12.2013 елемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан яисә «Сельская новь» газетасында, №ФС7-4770 2007 ел, 30.11.2007 ел.;

2) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру http://aksubaevo.tatarstan.ru.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары гамәлдә, алар түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Иске Кыязлы авылы, Үзәк урам, 57 йорт Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Салымнар һәм җыемнар турында Татарстан Республикасы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләрне күрсәтеп, муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен кешегә җиткерелә.